ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 583-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 583-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2570-VI ДС

проект

Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге эчтәлектәге 16 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«16) «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә сәнәгать тармакларында махсус инвестиция контрактларын төзүгә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтле сәнәгать сәясәте өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән башкарма хакимиятнең федераль органы яисә башка федераль башкарма хакимият органы йөзендә Россия Федерациясеннән кала «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы исеменнән Татарстан Республикасы тора торган махсус инвестиция контрактларында катнашучылар – корыч җөйсез торбалар җитештерүче оешмалар, – махсус инвестиция контрактын имзалау елына кадәрге календарь елның 1 нче көненнән дә иртәрәк исәпкә алынмаган махсус инвестиция контрактында каралган, капиталь инвестицияләр күләме 50 миллиард сумнан ким булмаган инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен яңа төзелгән яки сатып алынган мөлкәткә карата. Ташлама күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә алганнан соңгы айның 1 нче көненнән башлап бирелә, әмма махсус инвестиция контракты төзелгән айның 1 нче көненнән дә иртәрәк түгел, махсус инвестиция контракты гамәлдә булу вакытына, әмма 10 елдан да артык түгел.».

**2 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 94 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге $2^1$ өлешне өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы территориясендә корыч җөйсез торбалар җитештерү буенча капиталь инвестицияләр күләме 50 миллиард сумнан ким булмаган инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы 0 процент күләмендә билгеләнә.»;

2) 3 өлештә «1 һәм 2 өлешләрендә» сүзләрен «1, 2 һәм $2^1$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының**
**3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында**
**катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына**
**салым буенча салым ставкасын билгеләү турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына**
**үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

Закон проекты Татарстан Республикасына инвесторларны җәлеп итүне стимуллаштыру максатыннан эшләнгән һәм яклар булып Россия Федерациясе белән беррәттән Татарстан Республикасы да торган махсус инвестиция контрактларында катнашучыларга, капиталь кертемнәр күләме 50 миллиард сумнан ким булмаган корыч җөйсез торбалар җитештерү буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыручыларга салым ташламалары бирү мөмкинлеген күздә тота.

Закон проекты исәпләнгән салым суммасының 4,55 проценты күләмендә мөлкәткә салым түләүне һәм оешмаларның Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле табышына салым түләүдән азат итүне күздә тота.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.

2025 елдан 2034 елга кадәрге чорга капиталь кертемнәр күләме 50 миллиард сумнан ким булмаган корыч җөйсез торбалар җитештерү буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар мөлкәтенә салым буенча ташламалар суммасы алдан бәяләү буенча, 4 млрд сум тәшкил итәргә мөмкин, оешмаларның табышына салым буенча – 5,2 млрд сум.